**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию домашних свиней и диких кабанов африканской чумой свиней и угрозой ее распространения

В связи с выявлением заболевания домашних свиней и диких кабанов африканской чумой свиней и угрозой ее распространения, в соответствии со статьями $3^1$, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 28 января 2021 года № 37 **постановляю**:

1. Установить ограничительные мероприятия (карантин) по африканской чуме свиней на территориях эпизоотических очагов, угрожаемых зон и зоны наблюдения, определенных пунктом 2 настоящего Указа, с 12 августа 2022 года до особого распоряжения.

2. Определить:

а) эпизоотические очаги в пределах следующих отдельных территорий Республики Татарстан:

часть территории охотничьего хозяйства «Албаевское» в муниципальном образовании «Мамадышский муниципальный район», используемой акционерным обществом «Аэросервис», радиусом 300 м от географических координат: 55,838327° северной широты и 50,823172° восточной долготы;

часть территории охотничьего хозяйства «Куйбышевское» в муниципальном образовании «Спасский муниципальный район» радиусом 300 м от географических координат: 54,964428° северной широты и 49,189794° восточной долготы;

территория личного подсобного хозяйства по улице Центральная, дом 24, села Никольское в Никольском сельском поселении муниципального образования «Спасский муниципальный район»;

б) угрожаемые зоны в пределах территорий, прилегающих к эпизоотическим очагам, радиус которых составляет не менее:

5 км от границ эпизоотического очага, включая границы села Никифорово, села Сартык муниципального образования «Мамадышский муниципальный район»;

5 км от границ эпизоотического очага, включая границы села Красная Слобода, деревни Красный Вал, деревни Ржавец муниципального образования «Спасский муниципальный район»;

10 км от границ эпизоотического очага, включая границы села Никольское, деревни Гулюши, села Бугровка, села Антоновка, деревни Отрада, села Татарская Тахтала, поселка Мартышачий, поселка Фермы № 2 совхоза «КИМ», поселка совхоза «КИМ», села Гусиха, села Щербеть, села Красная Слобода муниципального образования «Спасский муниципальный район»;

в) зону наблюдения в пределах границ муниципальных образований «Аксубаевский муниципальный район», «Алексеевский муниципальный район», «Алькеевский муниципальный район», «Альметьевский муниципальный район», «Апастовский муниципальный район», «Арский муниципальный район», «Атнинский муниципальный район», «Балтасинский муниципальный район», «Буинский муниципальный район», «Верхнеуслонский муниципальный район», «Высокогорский муниципальный район», «Дрожжановский муниципальный район», «Елабужский муниципальный район», «Заинский муниципальный район», «Зеленодольский муниципальный район», «Кайбицкий муниципальный район», «Камско-Устьинский муниципальный район», «Кукморский муниципальный район», «Лаишевский муниципальный район», «Мамадышский муниципальный район», «Менделеевский муниципальный район», «Нижнекамский муниципальный район», «Новошешминский муниципальный район», «Нурлатский муниципальный район», «Пестречинский муниципальный район», «Рыбно-Слободский муниципальный район», «Сабинский муниципальный район», «Спасский муниципальный район», «Тетюшский муниципальный район», «Тукаевский муниципальный район», «Тюлячинский муниципальный район», «Чистопольский муниципальный район», за исключением территорий предприятий по убою свиней и переработке продуктов их убоя или убойных пунктов, перерабатывающих цехов, оборудованных для этих целей (далее – предприятия по убою и переработке), и (или) хозяйств, отнесенных к компартментам III и IV.

3. Запретить:

а) в эпизоотических очагах:

в хозяйствах, осуществляющих содержание свиней:

посещение территории посторонними лицами, кроме персонала, выполняющего производственные (технологические) операции, в том числе по обслуживанию свиней, специалистов органов и организаций, входящих в систему Государственной ветеринарной службы Российской Федерации, и привлеченного для ликвидации очага персонала, лиц, проживающих и (или) временно пребывающих на территории, признанной эпизоотическим очагом;

перемещение и перегруппировку свиней;

ввоз (ввод) и вывоз (вывод) свиней;

убой свиней;

вывоз продукции животноводства и растениеводства, включая корма;

въезд и выезд транспортных средств (за исключением транспорта, задействованного в мероприятиях по ликвидации эпизоотического очага и (или) по обеспечению жизнедеятельности людей, проживающих и (или) временно пребывающих на территории хозяйства);

в охотничьих угодьях и на иных территориях, являющихся средой обитания дикого кабана:

заготовку дикого кабана на мясо, для изготовления чучел, на иные цели;

заготовку кормов и подстилочного материала для свиней;

охоту, за исключением охоты в целях регулирования численности охотничьих ресурсов;

б) в угрожаемых зонах:

вывоз свиней;

реализацию свиней и продуктов убоя свиней непромышленного изготовления;

вывоз и пересылку, включая почтовые отправления, продуктов убоя свиней и продуктов их переработки, отходов свиноводства, оборудования и инвентаря, используемого при содержании свиней, проведение сельскохозяйственных ярмарок, выставок (аукционов) и других мероприятий, связанных с передвижением, перемещением и скоплением свиней;

заготовку на территории угрожаемой зоны и вывоз кормов, за исключением комбикормов промышленного производства и фуражного зерна, прошедших термическую обработку при температуре не менее 70 °C, обеспечивающую их обеззараживание;

все виды охоты, за исключением охоты в целях регулирования численности охотничьих ресурсов;

в) в зоне наблюдения:

ввоз свиней для воспроизводства, за исключением ввоза в хозяйства, отнесенные к компартментам III и IV, исключенные из зоны наблюдения в соответствии с пунктом 2 настоящего Указа;

ввоз свиней для откорма, за исключением ввоза свиней, вакцинированных в хозяйстве-поставщике против рожи свиней и классической чумы свиней не ранее 30 календарных дней до дня ввоза на территорию зоны наблюдения;

реализацию свиней и продуктов убоя свиней непромышленного изготовления;

проведение сельскохозяйственных ярмарок, выставок, торгов и других мероприятий, связанных с передвижением, перемещением и скоплением свиней, кроме случаев, связанных с производственной деятельностью хозяйств, отнесенных к компартментам III и IV, исключенных из зоны наблюдения в соответствии с пунктом 2 настоящего Указа;

выгульное содержание свиней, в том числе под навесами. В зоне наблюдения владельцы свиней должны обеспечить их содержание, исключающее контакт между свиньями и дикими животными;

убой свиней, за исключением убоя на предприятиях по убою и переработке с отбором проб биологического и (или) патологического материала для лабораторных исследований на африканскую чуму свиней в соответствии с пунктами 24–28 Ветеринарных правил осуществления профилактических, диагностических, ограничительных и иных мероприятий, установления и отмены карантина и иных ограничений, направленных на предотвращение распространения и ликвидацию очагов африканской чумы свиней, утвержденных приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 28 января 2021 года № 37 (далее – Правила);

вывоз свиней, кроме вывоза свиней из хозяйств, отнесенных к компартментам III и IV, исключенных из зоны наблюдения в соответствии с пунктом 2 настоящего Указа;

вывоз продуктов убоя свиней и продуктов их переработки, за исключением продукции промышленного изготовления, продукции непромышленного изготовления, переработанной или обеззараженной в соответствии с пунктом 58 Правил, и продукции, происходящей из хозяйств, отнесенных к компартментам III и IV, исключенных из зоны наблюдения в соответствии с пунктом 2 настоящего Указа;

охоту на дикого кабана, за исключением охоты в целях регулирования численности.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить планы мероприятий по ликвидации очагов африканской чумы свиней и предотвращению распространения возбудителя болезни на территории Республики Татарстан.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
12 августа 2022 года
№ УП-555

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йорт дуңгызлары һәм кабан дуңгызлары Африка дуңгыз чумасы белән чирләгәнгә, аларның иминлексезлеге һәм чир таралу куркынычы булу сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында**

Йорт дуңгызларының һәм кабан дуңгызларының Африка дуңгыз чумасы белән чирләве ачыклану белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$, 17 статьялары, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм**:

1. Әлеге Указның 2 пункты нигезендә билгеләнгән эпизоотия чыганаклары, куркыныч янаган зоналар һәм күзәтчелек зоналары территорияләрендә 2022 елның 12 августыннан аерым боерык чыгарылганга кадәр Африка дуңгыз чумасы буенча чикләү чаралары (карантин) кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләре чикләрендә эпизоотия чыганакларын:

«Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Алабай» аучылык хуҗалыгы территориясенең «Аэросервис» акционер җәмгыяте тарафыннан файдаланыла торган, төньяк киңлектәге 55,838327° һәм көньяк озынлыктагы 50,823172° географик координатларыннан 300 м радиустагы өлеше;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә «Куйбышев» аучылык хуҗалыгы территориясенең төньяк киңлектәге 54,964428° һәм көньяк озынлыктагы 49,189794° географик координатларыннан 300 м радиустагы өлеше;

«Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Никольский авыл җирлегенең Никольский авылындагы Үзәк урамда урнашкан 24 нче йорт шәхси ярдәмче хуҗалыгы территориясе;

б) эпизоотия чыганагы белән чиктәш булган, эпизоотия чыганагы чикләреннән радиусы ким дигәндә:

эпизоотия чыганагы чикләреннән, «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Никифорово авылы, Сәртек авылы чикләрен кертеп, 5 км;

эпизоотия чыганагы чикләреннән, «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Кызыл Бистә авылы, Красный Вал авылы, Ржавец авылы чикләрен кертеп, 5 км;

эпизоотия чыганагы чикләреннән, «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Никольский авылы, Гөлеш авылы, Бугровка авылы, Антоновка авылы, Отрада авылы, Татар Такталысы авылы, Мартышачий поселогы, «КИМ» совхозының икенче фермасы поселогы, «КИМ» совхозы поселогы, Гусиха авылы, Ширбәт авылы, Кызыл Бистә авылы чикләрен кертеп, 10 км булган территорияләр чикләрендә куркыныч янаган зоналарны;

в) дуңгыз чалу һәм аларны чалудан алынган продуктларны эшкәртү предприятиеләре яки бу максатларга җайлаштырылган хайван чалу пунктлары, эшкәртү цехлары (алга таба – хайван чалу һәм эшкәртү предприятиеләре) һәм (яки) III һәм IV компартментларга кертелгән хуҗалыклар территорияләреннән тыш, «Аксубай муниципаль районы», «Алексеевск муниципаль районы», «Әлки муниципаль районы, «Әлмәт муниципаль районы», «Апас муниципаль районы», «Арча муниципаль районы», «Әтнә муниципаль районы», «Балтач муниципаль районы», «Буа муниципаль районы», «Югары Ослан муниципаль районы», «Биектау муниципаль районы», «Чүпрәле муниципаль районы», «Алабуга муниципаль районы», «Зәй муниципаль районы», «Зеленодольск муниципаль районы», «Кайбыч муниципаль районы», «Кама Тамагы муниципаль районы», «Кукмара муниципаль районы», «Лаеш муниципаль районы», «Мамадыш муниципаль районы», «Менделеевск муниципаль районы», «Түбән Кама муниципаль районы», «Яңа Чишмә муниципаль районы», «Нурлат муниципаль районы», «Питрәч муниципаль районы», «Балык Бистәсе муниципаль районы», «Саба муниципаль районы», «Спас муниципаль районы», «Тәтеш муниципаль районы», «Тукай муниципаль районы», «Теләче муниципаль районы», «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлекләре чикләре кысаларында күзәтчелек зонасын.

3. Түбәндәгеләрне тыярга:

а) эпизоотия чыганакларында:

дуңгыз асрый торган хуҗалыкларда:

территориягә, производство һәм техник операцияләр башкаручы, шул исәптән дуңгыз караучы персоналдан, Россия Федерациясе Дәүләт ветеринария хезмәте системасына керүче органнар һәм оешмалар белгечләреннән, эпизоотия чыганагын бетерү өчен чакырылган персоналдан, эпизоотия чыганагы дип билгеләнгән территориядә яшәүче һәм (яисә) вакытлыча шунда торучы затлардан тыш, чит кешеләр керүне;

хайваннарны күчерү һәм яңадан төркемнәргә бүлүне;

дуңгызларны алып керүне (кертүне) һәм алып чыгуны (чыгаруны);

дуңгызларны чалуны;

терлекчелек һәм үсемлекчелек продукциясен, шул исәптән терлек азыгын чыгаруны;

транспорт кертүне һәм чыгаруны (эпизоотия чыганагын бетерү эшләрендә катнашучы һәм хуҗалык территориясендә яшәүче һәм (яисә) вакытлыча торучы кешеләрнең тормыш эшчәнлеген тәэмин итү чараларында файдаланылучы транспорттан тыш);

аучылык биләмәләрендә һәм кабан дуңгызы яшәгән башка территорияләрдә:

иткә сую, карачкы ясау өчен яки башка максатларда кабан аулауны;

терлек азыгы һәм дуңгызларга аслык әзерләүне;

кабан дуңгызының баш санын тиешле дәрәҗәдә тоту максатларындагы аудан тыш, ауны.

б) куркыныч янаган зоналарда:

дуңгызларны чыгаруны;

сәнәгать җитештерүе юлы белән чалынмаган дуңгызларны һәм дуңгыз чалу продуктларын сатуны;

дуңгыз чалу продуктларын һәм аларны эшкәртү продуктларын, дуңгыз асрау калдыкларын, дуңгыз асраганда файдаланыла торган җиһаз һәм инвентарьларны чыгару яисә почта аша салуны да кертеп, җибәрүне, дуңгызларны күчерү һәм туплау белән бәйле авыл хуҗалыгы ярминкәләре, күргәзмәләр (аукционнар) һәм башка чаралар үткәрүне;

сәнәгать җитештерүе юлы белән әзерләнә торган катнаш терлек азыгы һәм 70 °С югарырак температурада аларны йогышсызландыруны тәэмин итә торган фураж ашлыгыннан тыш, куркыныч янаучы зона территориясендә терлек азыгы әзерләүне һәм аны территориядән алып чыгуны;

кабан дуңгызының баш санын тиешле дәрәҗәдә тоту максатларындагы аудан тыш, башка ау төрләрен;

в) күзәтчелек зонасында:

III һәм IV компартментларга кертелгән һәм әлеге Указның 2 пункты нигезендә күзәтчелек зонасыннан чыгарылган хуҗалыклардан тыш, үрчетү максатларында дуңгызларны алып керүне;

күзәтчелек зонасы территориясенә алып кергән көнгә кадәр 30 календарь көн алдан дуңгызлардагы тире авыруына һәм классик дуңгыз чумасына каршы дуңгызлар сатучы оешмада вакцина ясалган дуңгызлардан тыш, симертү өчен дуңгызларны алып керүне;

сәнәгать җитештерүе юлы белән чалынмаган дуңгызларны һәм дуңгыз продуктларын сатуны;

III һәм IV компартментларга караучы һәм әлеге Указның 2 пункты нигезендә күзәтчелек зонасыннан чыгарылган хуҗалыкларның җитештерү эшчәнлеге белән бәйле очраклардан тыш, дуңгызларны күчерү һәм туплау белән бәйле авыл хуҗалыгы ярминкәләре, күргәзмәләр (аукционнар) һәм башка чаралар үткәрүне;

дуңгызларны япмыйча, шул исәптән төз лапаста асрауны. Күзәтчелек зонасында дуңгыз асраучылар дуңгызлар һәм кыргый хайваннар арасында элемтә булмаслык шартларны тәэмин итәргә тиеш;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 28 гыйнварындагы 37 номерлы карары нигезендә расланган Африка дуңгыз

чумасы таралуын һәм аның чыганакларын бетерүгә юнәлтелгән карантин һәм башка чикләүләр урнаштыру һәм аларны бетерү буенча профилактика, диагностика, чикләү һәм башка чараларны тормышка ашыру ветеринария кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 24–28 пунктлары нигезендә Африка дуңгыз чумасына лаборатория тикшеренүләре өчен биологик һәм (яисә) патологик материаллар пробасы алу өчен дуңгыз чалу һәм эшкәртү предприятиеләрендә дуңгыз чалудан тыш, дуңгызлар чалуны;

III һәм IV компартментларга кертелгән, әлеге Указның 2 пункты нигезендә күзәтчелек зонасыннан чыгарылган хуҗалыклардан тыш, дуңгызлар алып чыгуны;

сәнәгать җитештерүе юлы белән әзерләнгән, Кагыйдәләрнең 58 пункты нигезендә сәнәгать җитештерүе юлы белән әзерләнмәгән, эшкәртелгән һәм зарарсызландырылган продукциядән һәм III һәм IV компартментларга караучы һәм әлеге Указның 2 нче пункты нигезендә күзәтчелек зонасыннан чыгарылган хуҗалыкларда җитештерелгән продукциядән тыш, дуңгыз чалу продуктларын һәм аларны эшкәртү продуктларын алып чыгуны;

кабан дуңгызының баш санын тиешле дәрәҗәдә тоту максатларындагы аудан тыш, кабан дуңгызын аулауны.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә Африка дуңгыз чумасы чыганагын бетерү һәм Татарстан Республикасы территориясендә чирнең таралуын булдырмау чаралары планын эшләргә һәм расларга.

5. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2022 ел, 12 август
№ ПУ-555